# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**2024 елның 28 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004елның 28 июлендә 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә 2024 елның 26 ноябрендәге 15 сәгать 00 минутта, 2024 елның 28 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү».

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия жыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар жыенында катнашучы 74 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 42, бу 57 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 42 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлегенең Кыр Буасы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен - дөрес дип танырга.

2. «Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге Кыр Буасы авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;
- традицион күмү урыннарын ремонтлау, киртәләр урнаштыру, төзекләндерү;
- каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү». - соравы буенча карар кабул ителгән дип санарга.

Экономия барлыкка килгән очракта, аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл җирлеге башкарма комитетына җыен белән билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мәлки авыл җирлеге Башлыгы Ф.П.Поляков